**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 18 июнендәге 2093 номерлы карары**

## 2026 елда Бөтенроссия яшьләр көнен үткәрү кысаларында Казан шәһәре урам-юл челтәрендә транспорт чаралары хәрәкәтен чикләү турында

2026 елда Бөтенроссия яшьләр көнен үткәрү көнендә иминлекне тәэмин итү максатыннан, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль законга, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы «Төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында»гы карарына нигезләнеп:

1. **Карар бирәм**:

1.1. 2026 елның 27 июнендә 06:00 сәгатьтән 22:00 сәгатькә кадәр, кирәк булган очракта, Подлужная урамы буенча, Миллениум күперennән чыгу юлыннан алып Толстой урамына кадәр һәм Вишневский урамыннан чыгу юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен чикләүне кертергә;

1.2. 2026 елның 27 июнендә 15.00 сәгатьтән 22.00 сәгатькә кадәр, кирәк булган очракта, Миллениум күпере буенча, .Фатыйх Әмирхан урамыннан алып Вишневский урамына кадәрге участокта җәяүлеләр хәрәкәтен чикләүне кертергә;

1.3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.В.Сидоров):

1.3.1. вакытлыча юл билгеләрен урнаштыру һәм гамәлдәге юл билгеләрен каплау чараларын оештырырга;

1.3.2. транспорт чараларын куюны һәм аларның хәрәкәтен вакытлыча чикләү турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының

«Татарстан Республикасы рәсми порталы» дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган рәсми сайтында урнаштырырга;

1.3.3. кыска вакытлы аренда хезмәте күрсәтә торган электр самокатлары (WHOOSH һәм МТС.URENT) һәм велосипед («Яшел шәһәр») операторлары белән берлектә әлеге карарда күрсәтелгән участокларда шәхси мобильлек чараларын куеп торуны һәм аларның хәрәкәтен тыю буенча эш оештырырга;

1.4. Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитетына (А.М.Шайнуров) Казан шәһәре Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе (А.И.Салихов) белән берлектә юлларны йөк техникасы яки таранга каршы блоклар белән ябу эшен оештырырга;

1.5. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

2. **Тәкъдим итәм**:

2.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Р.Д.Габитов) әлеге карар нигезендә Казан шәһәре урам-юл челтәренең югарыда күрсәтелгән участокларында юл хәрәкәте иминлеген саклауны һәм оештыру-көйләү гамәлләрен башкаруны контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

2.2. Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) урам-юл челтәренең күрсәтелгән участокларында транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләүне кертү турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**